Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлегенең Варкләд торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019ел, 08 ноябрь №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Варкләд торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Варкләд авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-IIIгруппа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия армиясендә хезмәт итүче затлардан, иректән мәхрүм ителгәннәрдән тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Варкләд авылы урамнарын кардан чистарту.

3.Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Яңа Бәзәкә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы, Совет Рәисе М.М. Ногманов